Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Свердловец торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 17 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенең Свердловец торак пунктында граждannар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге Свердловец торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире 600 сум күләмендә 2024 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманыц 50% күләмендә 2 группа инвалидлар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнар, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баланың ата-аналары түли.
2. Алынган акчаларны Свердловец бистәсендә Карл Маркс урамындагы юлны ремонтлау (подряд килешүе буенча эш өчен түләү).

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Свердловец торак пунктында гражданнар җыены карары 02.11.2021нче елның 2 номерлы нигезендә спорт һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерүгә (башкарылган эшләр, хезмәт күрсәтүләр килешүе) һәм янгын гидрантын урнаштыруга (башкарылган эшләр килешүе буенча түләү) 11380,00 сум күләмендә җыелган гражданнарның үзара салым салу чаралары., Свердловец бистәсендәге Карл Маркс урамындагы юлны ремонтлауга җибәрергә (подряд килешүе буенча эш өчен түләү).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кармалы авыл җирлеге башлыгы А.Д. Кубышкин